

2023 ел Россия Президенты Владимир Путин Указы белән педагог һәм остаз елы дип игълан ителде. Педагог һөнәре кешедән зур белем генә түгел, күңел көчен, чыдамлылыгын да таләп итә. Авырлыкларга карамастан, бу тормышта укытучы хезмәтен сайлаган кешеләр булуы сөендерә.

Укытучы - дөньяны танырга, акны карадан, яхшыны яманнан аерырга өйрәтүче тылсымчы ул. Кешенең иң матур истәлекләре, иң изге хыяллары, иң беренче шатлык-куанычлары аның балачагы һәм үсмер чоры белән бәйләнгән. Менә шушы матур истәлекләр арасында шактый зур урынны мәктәп бусагасын атлап кергән көннән алып, зур тормышка озатып, соңгы кыңгырау чыңлаган көнгә кадәр бала белән һәрчак янәшәдә Укытучы атлый.       Ул аны белем дөньясына алып керә, хезмәт һәм иҗат шатлыгын тоярга өйрәтә, фикерләү сәләтен үстерә, дөньяга карашын формалаштыра, анардан шәхес тәрбияләүгә бөтен көчен куя. Укытучы хезмәте авыр да, җаваплы да, кызыклы да. Укытучы һөнәрен сайлау - тынгысызлык, эзләнү юлын сайлау, үз-үзенә һәм башкаларга искиткеч таләпчән булу, көндәлек тырыш, эзлекле хезмәт юлын сайлау дигән сүз ул. Бу язмамның герое да тормышның төрле этапларын үтеп, яшь буынны тәрбияләүдә фидакарь, батыр хезмәте белән халык рәхмәтен, ихтирамын казанып, бүгенге зур эш нәтиҗәләренә ирешкән олуг йөрәкле шәхес – Сания Спартак кызы Саляева турында булыр.

Рузаевка районы Татар Пешлә авылында Спартак абзый белән Рокыя апаның гаиләсендә тупчек тагы бер кыз бала булып дөньяга Санияләре аваз сала. Сабыйлык, балалык чорын үтеп, туган авылы урта мәктәбендә белем алганнан соң, Сания, укытучы булу теләге белән, Казан дәүләт педагогия институтының тарих-филология факультетына укырга керә. Телләргә карата булган сәләте татар, рус теле фәннәрен яхшы үзләштереп, вузны уңышлы тәмамлый. Һади Такташ Юбилей чараларының берсендә укытучыбыз Фоат Галимулла улы Галимуллин Сания студенты турында сокланып искә алган иде: «Мордовиядән килгән бу мишәр кызының уңганлыгына, булганлыгына сокланып укыттым. Аның кебек шигырь яттан сәнгатьле сөйләүче укучыларым аз булды...»

Вузны тәмамлаган яшь белгеч туган авылы урта мәктәбенә татар теле һәм татар әдәбияты предметларыннан укучыларга ныклы белем бирә башлый. Эшен чын кvнелдән яратып, ботен белемен, энергиясен, кочен кызганмыйча башкара ул. Тирән белемле, гел яналыкка омтылучы укытучы апаларын балалар да vз итә. Дәрес темаларын яратып, алдынгы педагогик технологияләрне куллангач, укучыларнын фән белән кызыксынулары арта, нәтижәләр дә унай якка vзгәрә бара. Ин авыр, ин кvп коч-энергия, сабырлык, тvземлек, акыллылык таләп итvче һонәрен Сания Спартак кызы яратып башкара; конне тонгә ялгап эшли, дәресенә әзерләнә, укучыларнын дәфтәрләрен тикшерә. Ул коне буе мәктәптә балаларга белем бирә, оендә гаиләсе, кырык эше кырыкка ярылып ятса да vз һонәренә тугъры булып кала. Барысына да ирешергә, намус белән эшләргә, балаларны яратырга, хезмәттәшләрен хормәт итәргә остазлары - наставниклары буларак югары белем йортыннан vзләштереп кайта. Аннары vзе дә регионыбыз укытучыларына остаз буларак ярдәм итә.
Үтә тырыш, максатына ирешvчән булуы Сания Спартак кызына туган теле фәнен укытуда югары vрләр яуларга ярдәм итә. Анын укучылары ел саен фән олимпиадаларынын муниципаль, республика, тобәкара, халыкара олимпиадаларында, ижади эшләр конкурсларында бvген дә жинvчеләр. Шулай, быел Казанда vткән тобәкара олимпиадасында Рузаевка районы Татар Пешлә урта мәктәбе 11 класс укучысы Кузикова Самира призерлык яулап кайта. Ә Камила Чугунова – VII Халыкара олимпиадасы (2019 ел) призеры. Сания Спартаковна М.Е.Евсевьев исемен йорткән педагогия университетында татар теле буенча белем алган укучылары очен (Овчинникова Карина, Новикова Айсылу, Бадамшин Адель...) бvген дә остаз.
Укытучылык вазифасын башкару остенә авыл халкы белән тыгыз элемтәдә эшләргә, торле чараларында катнашырга туры килә ана. Гаиләдә яхшы тормыш иптәше, тәртипле әни, мәктәптә унган укытучы булу бик жинел булмагандыр. Сынатмый ул, нинди генә эшкә кушсалар да жиренә житкереп башкара. Сания Спартаковна Саляева vз эше һәм укучылары турында бик теләп сойли, vз эше очен ботен кvнел белән борчылуы кvренә:
- Жир йозендәге һәр халыкнын vз теле, vз тамырлары һәм традицияләре бар. Туган тел укытучысы буларак минем алда милли телгә, гореф – гадәтләргә сакчыл караш тәрбияләv бурычы тора. Бу туган телен яратучы, язмышын туган як киләчәге белән тыгыз бәйләvче кешене формалаштырырга ярдәм итә. Халыкнын мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен ойрәнә башлагач, ин элек анын ана соте белән кергән телен vзләштерvдән башларга кирәк. Барысы да монын белән ризалашыр дип уйлыйм. Балаларда патриотик хисләр тәрбияләv дә туган телне ойрәнv нәтижәсендә башкарыла. Хезмәтем - горурлыгым минем.
Чын укытучы булу очен, укытучы дипломы, категориясе, бvләкләре, исемнәре аз, тагын бер зур сәнгатькә ия булырга кирәк – балаларны ярату сәнгате. Укучыларны туган телгә һәм әдәбиятка ойрәтеп, Сания Спартак кызы Саляева vз укучыларын халык мәдәниятенә һәм гореф-гадәтләренә ойрәтә. Укытучы vз предметын укытуга ижади якын килергә тырыша, моһим нәтижә бирә торган инновацион технологияләр кертә, проблемалы, vсештә булган укытуны, шулай ук уен моментларын, проект эшләрен, тест биремнәрен куллана. Болар барысы да яхшы нәтижә бирә.
Республика кvләмендә бvген дә зур тәжрибәле, эрудицияле, талантлы педагог бу эшендә дә сынатмый. Мәктәптә татар теле һәм әдәбияты кабинеты жиһазландырыла. Кабинеты республика кvләмендә vткәрелгән смотр-конкурста I урынга лаек була һәм Мордовия Республикасы мәгариф министрлыгынын «Ин яхшы татар теле һәм әдәбияты

кабинеты» таныклыгы тапшырыла.
Яшь укытучыларга да, олкән яшьтәгеләргә дә ул vрнәк, эш тәҗрибәсен алар белән теләп уртаклаша, аларга методик ярдәм кvрсәтә. Ботенроссия кысаларында vткән чараларда даими эш тәҗрибәсе белән уртаклашып килә. Шулай, 2014 елда Ботенроссия укытучылары съездында эш тәҗрибәсе белән уртаклаша һәм ирешкән унышларын бәяләп «Почетный работник общего образования» дигән олы бvләк белән бvләкләнә. Ә 2019 елда vткән «Заман укытучысына – заманча таләпләр» Ботенроссия мәгариф һәм фән хезмәткәрләре пленар утырышында «Мәгарифтәге казанышлары очен» медале тапшырыла. Бу бvләкләр белән Сания Спартаковнанын хезмәтен Татарстан билгеләп vтә. Хезмәтенә бәя бирелеп, кvпләгән Мактау грамоталары белән Мордовиядә дә бvләкләнде. Мордовия кvләмендә атказанган татар теле һәм татар әдәбияты исеменә лаек укытучы ул!
Кешелеклелеге, игътибарлы һәм ихтирамлы булуы, кvркәм сыйфатлары жаннарны жылыта, тормышка ямь ости. Киләчәктә Сания Спартак кызына тагын да зуррак vрләр яуларга, балаларынын, оныкларынын игелеген кvреп тынычлыкта, сәламәтлектә гомер кичеререгә язсын. Авыр һәм мактаулы хезмәтендә зур унышлар, соенеч-шатлыклар кvп булсын. Безгә - Мордовиябезнен мәгариф ветераннарына Татар Пешлә мәктәбе ирешкән унышларына куанып яшәргә насыйп булсын.

**Наилә НАСЫРОВА**